Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

05.02.2024 ел Менделеевск ш. №233

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Менделеевск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» Менделеевск муниципаль районы Советының 2023 елның 18 декабрендәге 229 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Менделеевск муниципаль районы халкының фикерен исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү белән кушымта итеп бирелә торган карта-схема нигезендә килешергә.
2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.ru урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район Советы рәисе Р.И.Беляев

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү турында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2024елның 5 февралендәге 233 номерлы карарына 1 нче кушымта

